РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 25 » 08 2023 г. №1306

2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларының кайнар туклануын оештыру турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 29.12.2012 ел, 273-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль оешмаларда башлангыч белем бирү программалары буенча белем алучыларны бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында” 2022 елның 14 сентябрендәге 991 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Россия Федерациясендә 2023 елга айлык акчалата һәм башка акчалата түләүләр турында” 2022 елның 1 сентябрендәге 934 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 20.10.2022 № 1122 Карары, РФ Баш дәүләт санитар табибының «СанПин 2.4.5.2409-08 раслау турында » 28.09.2020 № 45 карары, РФ Баш дәүләт санитар табибының 28.09.2020 ел, № 28 "СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында" карары, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында балансы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Башкарма комитеты
карар бирә:

1. Расларга:

1.1. 2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны әлеге карарга кушымта

нигезендә өстәмә социаль ярдәм итүгә мохтаҗларны тукландыруны оештыру тәртибе турында нигезләмәне;

1.2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар өчен бер укучыга көнгә кайнар туклану бәясен - 64 сум 19 тиен күләмендә;

1.3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар өчен (иртәнге аш, төшке аш) кайнар туклану бәясен:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга түләүләрнең айлык акчалата һәм башка төрләре турында» 2022 ел, 01.09.2022 ел, № 934 карары нигезендә, Урыссу шәһәр тибындагы поселогында 61 сум 80 тиен күләмендә, уку чорында бер укучыга көненә 8 сум 80 тиен күләмендә субсидияләрдән һәм һәр уку көненә ата - аналар түләве 53 сум 00 тиен күләмендә (иртәнге аш 13 сум 00 тиен, төшке аш 40 сум 00 тиен) түләүләрне;

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 01.09.2022 № 934 карары нигезендә, авыл җирендә уку чорында бер укучыга 58 сум 80 тиен бәяне, 8 сум 80 тиен күләмендә субсидияне, һәм һәр уку көненә ата-аналар түләвен - 50 сум 00 тиен (иртәнге аш - 13 сум 00 тиен, төшке аш - 37 сум тиен) күләмендә.

1.4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының расланган гомуми белем бирү учреждениеләре тарафыннан белем алучыларга өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләргә, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларга, инвалид-балаларга бер укучыга айлык акчалата түләү (иртәнге аш, төшке аш) ата-аналарны (законлы вәкилләрне) ата-ана взносларын түләүдән азат итү юлы белән, укучылар исемлегенә ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан:

- Урыссу ш.т. поселогында 61 сум 80 тиен күләмендә;

- авыл җирлегендә 58 сум 80 тиен күләмендә.

1.5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы укучыларга ике тапкыр кайнар туклану (иртәнге аш, төшке аш) бәясе, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларына, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр һәм Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән гражданнар, шулай ук махсус хәрби операцияләрдә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гаиләләр әгъзаларына :

- Урыссу ш.т. поселогында - 61 сум 80 тиен күләмендә;

- авыл җирендә - 58 сум 80 тиен күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны өйдә коры паек белән тәэмин итәргә яки әлеге карар белән билгеләнгән күләмдә ике тапкыр туклану бәясенә тиң акчалата эквивалентта туклану өчен компенсация түләргә.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының мәгариф оешмалары җитәкчеләренә:

3.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар азык белән тәэмин итәргә.

3.2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар тукландыруны оештырырга.

3.3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә түбәндәгеләрне төзергә:

- куркынычсыз, сыйфатлы, рациональ, балансланган туклану белән тәэмин итүне объектив тикшереп тору максатларында, әзер ризыкларның сыйфатын тикшереп торуны гамәлгә ашыру, санитария-гигиена таләпләрен үтәү, белем алучыларның туклануын күзәтү максатларында, Бракераж комиссиясен;

- мәктәп ашханәсе эшен тикшереп тору, меню нигезендә әзерләнгән азыкның сыйфатын һәм күләмен тикшерү, мәктәптә туклануны оештыруның оптималь шартларын һәм формаларын булдыруга ярдәм итү максатларында, гомуми белем бирү учреждениесендә - Туклануны оештыруның сыйфатын тикшереп тору комиссиясен.

3.4. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары нигезендә кайнар туклану оештыруга производство контролен үткәрергә.

3.5. Укучыларны сыйфатлы һәм сәламәт тукландыру мәсьәләләрен хәл итү, гомуми белем бирү учреждениесендә сәламәт туклану нигезләрен пропагандалау, гомуми мәктәп ата-аналар комитеты белән хезмәттәшлектә гамәлгә ашырылырга тиеш.

3.6. Ата-ана контролен оештыруны гомуми мәктәп комиссиясендә катнашындагы ата-аналарны һәм укучыларны анкеталаштыру рәвешендә гамәлгә ашырырга.

4. «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУның мәгариф бүлеге начальнигына кайнар туклану нормаларын үтәүне һәм сәламәтлекне ныгытуны тәэмин итү, укучыларны сыйфатлы туклану белән тәэмин итү өчен тиешле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә атна саен чыгуны гамәлгә ашырырга.

5. «2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклandыруны оештыру турында»

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 09.01.2023 ел, №3 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.А. Абрамов
тел. 2-42-23

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
20__ел № карарына кушымта _____

Өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларга 2023 елда туклануны оештыру тәртибе турында нигезләмә

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар туклandыруны оештыру максатларында укучыларның түбәндәге категориясенә эшләнде:

1.1. Россия Федерациясе Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 05 маендагы 431 номерлы Указы нигезендә - 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларны ике мәртәбә түләүсез туклану (иртәнге аш һәм төшке аш) белән тәэмин итәргә.

1.2. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон нигезендә - ике тапкыр ташламалы бушлай туклану (иртәнге аш һәм төшке аш) сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларга һәм инвалид балаларга бирелә.

1.3. «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 20.10.2022 № 1122 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренең укучы әгъзаларына бушлай ике тапкыр ашату (иртәнге һәм төшке аш) ташламасы бирелә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар, хәрбиләр һәм затлар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче гражданнар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләкләре белән үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, шулай ук югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гаиләләр (гаилә әгъзалары) гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнар (үлгәннәр) гаиләләрендәге укучылар.

1.4. Укучыларга адреслы социаль ярдәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклану (төшке аш) өчен ата-ана кертемнәрен түләүдән өлешчә азат итү юлы белән гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләр бирелә:

- ата-аналары 1 нче һәм 2 нче инвалидлык төркеменә ия булган балаларга;
- опекадагы балаларга.

2. Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның кайнар туклануын оештыру өчен комиссия төзелә, алар составына гомуми белем бирү учреждениесенең педагоглар коллективы һәм ата-аналар комитеты вәкилләре арасыннан туклануны оештыру өчен җаваплы җитәкче керә.

Комиссия уку елы башында һәм, кирәк булган саен:

- тәкъдим ителгән гаризаларны карый һәм укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карарлар кабул итә;
- 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрне, аларның торак шартларын тикшерә, аларның матди хәлен, гаиләдә балалар һәм иждивенецлар санын билгели, укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карар кабул итә, тикшерү нәтиҗәләре белән беррәттән актта әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта формасы буенча теркәлә;
- өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның исемлекләрен раслый;
- бирелгән төшке ашларның билгеләнгән тәртиптә расланган менюга туры килүен тикшерә.

Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- кагыйдә бозулар белән әзерләнгән ашамлыкны менюдан алырга;
- медицина хезмәткәре белән берлектә китерелгән азык-төлекнең сыйфатын тикшерергә, үлчәүне гамәлгә ашыруны тикшереп торырга;
- тикшерүләр нәтиҗәләре буенча хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрүне белем бирү оешмасы директорыннан таләп итәргә.

3. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе:

- укучыларны бушлай туклану белән тәэмин итү буенча боерыклар чыгара;
- Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә бушлай туклану белән колачланган укучыларның исемлекләрен тәкъдим итә.

4. Сыйныф җитәкчеләре:

- әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтадагы форма буенча түләүсез туклану белән тәэмин итүгә ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) гариза кабул итәләр;
- гаризаларны алган көннән алып өч көн эчендә комиссия каравына җибәрәләр;
- сыйныфта укучыларның туклануы исәбен алып баралар;
- укучылар һәм ата-аналар арасында укучыларның тулы кыйммәтле туклануы зарурлыгы турында аңлату эшләре алып баралар;
- барлык сыйныф укучыларының ашханәдә туклануын тикшереп торалар;
- укучыларның туклануы вакытында ашханәдә булалар;
- башлангыч сыйныфларда «Дөрес туклану турында сөйләшү» курсы кертелә;

5. Ата-аналар (законлы вәкилләр) тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы булалар.

6. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының барлык гомуми белем бирү учреждениеләренә кагыла.

Кушымта №1<br>2023 елда Татарстан Республикасы<br>Ютазы муниципаль районының<br>өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ<br>башлангыч, төп гомуми һәм урта<br>гомуми белем бирү учреждениеләре<br>укучыларының кайнар туклануын<br>оештыру тәртибе турындагы<br>Нигезләмәгә 2 нче кушымта

"________________________________" МБУның_______ сыйныфы укучысы

гаиләсен тикшерү АКТы

Ф.И.А.и.______________________________________________________________

_________________________________ ______________________ гаиләсе

_________________________________ адресы буенча фатирда (өйдә) яши
____________________________________________________________________

Гаиләдә укучы балалар саны_______, иждивенецлар саны____________

Гаиләнең матди хәле __________________________________________

Гаилә әгъзасына гомуми керем ________________сум тәшкил итә ( ата-аналар гаризасы буенча)
Ата-аналарның эш урыны, биләгән вазыйфасы, уртача айлык хезмәт хакы:
________________________________________________________________________
________________________________________________________________

Өстәмә белешмәләр______________________________________________

Гаиләнең торак шартларын һәм гаиләнең матди хәлен тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия карар кабул итә:

_______ сыйныф укучысы ______________________________(Ф.И.А.и.)
өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ (мохтаҗ түгел).

Комиссия рәисе: __________________________ (_____________)
Комиссия әгъзасы: ___________(________________________________)
Комиссия әгъзасы:_________________________________(________________)
Комиссия әгъзасы:___________________________________(________________)
Сыйныф җитәкчесе: ________________________ (____________)

2 номерлы кушымта
2023 елда Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ
башлангыч, төп гомуми һәм урта
гомуми белем бирү учреждениеләре
укучыларының кайнар туклануын
оештыру тәртибе турындагы
Нигезләмәгә 2 нче кушымта

Директор
____________________________
____________________________

кемнән__________________________
(Ата-ана, законлы вәкил Ф.И.А.и.)

Гариза

Минем улым (кызым) ______________________________________________ га

"______________ _________________" МББУның ________ сыйныф укучысына

ташламалы туклану тәкъдим итү мөмкинлеген каравыгызны сорыйм

Түбәндәге документлар теркәлә:
- гаилә составы турында белешмә;
- күп балалы ана таныклыгының күчермәсе;
- гаиләнең аз тәэмин ителгән булуы турында белешмә.

Дата ___________________

Имза___________________